РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
03.08.2018 №3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Кибәче авыл җирлеген төзекләндерү
кагыйдәләренә үзгәртүләр кертү проекты буенча
ачык тыңлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.11.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясына һәм «Олы Кибәче авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар турында Нигезләмә»гә таянып,

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәртүләр кертү турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 2018 елның 6 сентябренә 9.00 сәгатьтә;

2.2. ачык тыңлауларның дәвамлылыгы-ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр карар проекты басылып чыккан көннән алып 30 көннән дә артмаска тиеш;

2.3. үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Кибәче авылы, Ф. Энгельс урамы, 75 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Кибәче авыл клубы бинасы

2.4. төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш. т. Б. , Г.Закиров урамы, 52 йорт адресы буенча тапшырылырга мөмкин.

3. Авыл җирлеге секретарена:

- халык алдында тыңлауларга әзерлекне, гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны, гавами тыңлаулар үткәрүне тәэмин итәргә;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru

әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты белән бергә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru -Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru адресы буенча.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин